КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 март г.Казань № 129

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләмен исәпләү һәм гаиләнең җан башына уртача кереме күләме хакындагы белешмә кәгазен бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

12 пунктның өченче һәм дүртенче абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктта:

икенче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «– Татарстан Республикасы территориясендә никахлашуны дәүләт теркәвенә алган очракта» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы карары редакциясендә)

Балалар кирәк-яракларының бүләк комплекты
составы

| Т/с | Әйбернең исеме | Саны, данә |
|---|---|---|
| 1. | Малайлар өчен һәм кызлар өчен ясле универсаль комбинезон-трансформер, үлчәме 24/74 | 1 |
| 2. | Яңа туган балалар өчен мендәр-кокон, үлчәме 90 × 60, ян-якларының биеклеге 15 см | 1 |
| 3. | Киез итекләр, үлчәме 14 | 1 |
| 4. | Балалар өчен сырылган юрган, үлчәме 118 × 118 | 1 |
| 5. | Балалар өчен йөнтәс әйберләр җыелмасы (чигүле халат, капюшонлы мунча сөлгесе, кечкенә бияләйләр, кечкенә башмаклар) | 1 |
| 6. | Балалар чүпрәкләре MIDI 4 – 9 кг (төргәктә 54 данә) | 2 |
| 7. | Яңа туган балалар өчен җыелма (комплектта кечкенә кофта, кечкенә чалбар һәм баш киеме) | 1 |
| 8. | Яна туган балалар өчен бәздән биләү чүпрәге, үлчәме 75 × 120 | 2 |
| 9. | Яңа туган балалар өчен фланель тукымадан биләү чүпрәге, үлчәме 75 × 120 | 2 |
| 10. | Балалар киеме өчен кер юу порошогы, авырлыгы 2 400 г | 1 |
| 11. | Балалар бәдрәф сабыны, авырлыгы 190 г | 1 |
| 12. | Балалар сабыны, авырлыгы 135 г | 1 |
| 13. | Балалар өчен гель-шампунь, 300 мл | 1 |
| 14. | Тән өчен җиңелчә крем, 300 мл | 1 |
| 15. | Сыек сабын, 300 мл | 1 |
| 16. | Әйбер төрү-салу өчен тоткалы тартма | 1 |

_________________________